ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

ПРИКАЗ

03.11.2016 г. Казань № 104.1-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләре өчен эш вакыты юнәлеше буенча эш стажына кертеп исәпләнә торган вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеген раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 22 сентябрендәге № 676 карары нигезендә хезмәт өчен түләүнең яңа системалары кертелүгә бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

1. «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләре өчен эш вакыты юнәлеше буенча эш стажына кертеп исәпләнә торган вазыйфаларның (һөнәрләрнең) кушымта итеп бирелүче исемлеген расларга.

2. Әлеге боерык 2016 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитетының
03.11.2016 № 104.1-од
боерыгына кушымта

«Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» дәүләт бюджет учреждениесе хезмәткәрләре өчен эш вакыты юнәлеше буенча эш стажына кертеп исәпләнә торган вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге

1. Архив директоры, архив директорлары урынбасарлары.
2. Архив документларының сакланышын тәэмин итү лабораториясе директоры (башлыгы, мөдире), архивист.
3. Археограф.
4. Палеограф.
5. Архив методисты.
6. Архив документларының рәссамы-реставраторы; фондларны саклаучы.
7. Архив документларының сакланышын тәэмин итү лабораториясе белгече.
8. Дәүләт (муниципаль) хакимиятнең закон чыгару һәм башкарма органы, эшләр алып бару хезмәте архивы, дәүләт архивының төп эшчәнлек юнәлешенә туры килүче, функциональ вазыйфаларына архив хезмәте һәм китапханәләр эшчәнлеген җайга салу, тикшереп тору керә торган фәнни оешма архивының, шулай ук анда эшләү аудиовизуаль документлар булдыруга һәм саклауга, документларның физик-химик сакланышын тәэмин итү буенча махсус технологик җайланмаларга хезмәт күрсәтүгә, инженер-техник мәгълүмат системаларын проектлауга һәм аларга хезмәт күрсәтүгә бәйле башка оешма белгече.
9. Дәүләт (муниципаль) хакимиятнең закон чыгару һәм башкарма органы, эшләр алып бару хезмәте архивы, дәүләт архивының төп эшчәнлек юнәлешенә туры килүче, функциональ вазыйфаларына архив хезмәте һәм китапханәләр эшчәнлеген җайга салу, тикшереп тору керә торган фәнни оешма архивының, шулай ук анда эшләү аудиовизуаль документлар булдыруга һәм саклауга, документларның физик-химик сакланышын тәэмин итү буенча махсус технологик җайланмаларга хезмәт күрсәтүгә, инженер-техник мәгълүмат системаларын проектлауга һәм аларга хезмәт күрсәтүгә бәйле башка оешманың секторы мөдире (сектор башлыгы).
10. Дәүләт (муниципаль) хакимиятнең закон чыгару һәм башкарма органы, эшләр алып бару хезмәте архивы, дәүләт архивының төп эшчәнлек юнәлешенә туры килүче, функциональ вазыйфаларына архив хезмәте һәм китапханәләр эшчәнлеген җайга салу, тикшереп тору керә торган фәнни оешма архивының, шулай ук анда эшләү аудиовизуаль документлар булдыруга һәм саклауга, документларның физик-химик сакланышын тәэмин итү буенча махсус технологик җайланмаларга хезмәт күрсәтүгә, инженер-техник мәгълүмат системаларын проектлауга һәм аларга, югары уку йортларының, урта махсу уку йортларының архивларда, эшләр алып бару

хезмәтләрендә эшләү өчен кадрлар әзерләүче профессор-мөгәллим составына хезмәт күрсәтүгә бәйле башка оешманың бүлек башлыгы (бүлек мөдире)

11. Нәшриятлар һәм вакытлы матбугат басмалары мөхәррире, корректоры, дизайнеры.